| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

5 март 2019 ел Шалты авылы № 2

Язгы ташу чорында
оештыру чаралыры турында

Язгы ташу чорында кискен су басу сәбәпле халыкның иминлеген һәм биналарны, күперләрне, гидротехник корылмаларны саклау максатында

карар бирәм:

1. №1 кушымта нигезендә авылда язгы ташуга каршы комиссия төзергә
2. 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны һәм авыл территорисен саклау чаралары планын расларга (№2 кушымта)
3. "Берлек" ҖЧҖ-нә язгы ташу чорында техник чараларны вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
4. Язгы ташу чорына урыннарда җаваплы хезмәткәрләрнең, язгы ташуга каршы комиссия әгъзаларының тәүлек буе кизү торуын билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Фаткуллин З.Х.

Баулы муниципаль районы
Шалты авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 5 марттан
№ 2 карарына № 1 кушымта

Язгы ташуга каршы комиссия составы

1. Фаткуллин З.Х. — Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе
2. Абдуллин Н.Х. — Хуҗалык идарәчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча)
3. Набиуллин И.С. — Мәктәп директоры, балалар белән инструктаж үткәрү өчен җаваплы (килешү буенча)
4. Канипова Г.С. — ФАП мөдире, балалар белән инструктаж үткәрү өчен җаваплы, беренче ярдәм күрсәтү (килешү буенча)
5. Валиев А.В. — Газ хезмәте күрсәтү буенча слесарь, газүткәргеч өчен җаваплы (килешү буенча)
6. Забиров Р.Р. — Новозареченск бистәсе янгынга каршы хезмәтнең аерым посты башлыгы (килешү буенча)
7. Фахриев М.М. — Баулы РЭСы башлыгы (килешү буенча)

Шалты авыл җирлеге
башкарма комитеты сәркатибе Валиев Э.А.

Баулы муниципаль районы
Шалты авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 5 марттан
№ 2 карарына № 2 кушымта

2019 елгы язгы ташу чорында чаралар ПЛАНЫ

| № | Чара | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Язгы ташуга каршы комиссия төзү | 12 мартка кадәр | Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Фаткуллин З.Х. |
| 2 | Хуҗалык белгечләре; медпункт мөдире, мәктәп һәм клуб директорлары тарафыннан язгы ташу чорында чаралар турында халыкка инструктаж | 12 мартка кадәр | Канипова Г.С. – килешү буенча<br>Набиуллин И.С. – килешү буенча<br>Абдуллин Н.Х. – килешү буенча |
| 3 | Иминият агентына су баса торган зонада яшәүче гражданнарның мөлкәтен иминиятләштерүне йөкләргә | 19 мартка кадәр | Сабитова З.Г. иминият агенты – килешү буенча |
| 4 | Авыл Советы депутатлары тарафыннан һәрбер хуҗалыкны карап чыгу | 16 мартка кадәр | Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Фаткуллин З.Х. |
| 5 | Боз, ташу суларын үткәрү буенча бригадалар төзү | | Абдуллин Н.Х. – килешү буенча |
| 6 | Тергәкләр тирәсендә боз кисәкләрен үзвакытлы үткәрүне тәэмин итәргә | | Абдуллин Н.Х. – килешү буенча |
| 7 | Төзү материаллары белән тәэмин итү | | Абдуллин Н.Х. – килешү буенча |
| 8 | Суүткәргеч торбаларны һәм күперләрне чистартуны оештырырга | | Абдуллин Н.Х. – килешү буенча |
| 9 | Юл буйларында маяклар урнаштыру | | Абдуллин Н.Х. – килешү буенча |
| 10 | Тыкрыкларны һәм юлларны кардан чистартырга | 19 мартка кадәр | Абдуллин Н.Х. – килешү буенча<br>Тухбатуллин З.М. – килешү буенча |
| 11 | Урамнарны яктырту өчен баганаларга лампочкалар урнаштыру | 19 мартка кадәр | Ситдиков З.С. – килешү буенча |
| 12 | Көймәләрнең сакланышын тикшерергә һәм ремонт үткәрергә | 19 мартка кадәр | Шалты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Фаткуллин З.Х. – килешү буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13 | Нефтебазада емкостьларны ныгыту | 19 мартка кадәр | Сахибуллина Р.Р. – килешү буенча |
| 14 | Авыл халкын эчәргә яраклы су белән тәэмин итүне оештыру | | Валиев А.В. – килешү буенча |
| 15 | Авыл халкын нормаль газ белән тәэмин итүне контрольдә тоту һәм алар белән куркынычсызлык техникасы буенча инструктаж үткәрү | | Валиев А.В. – килешү буенча |

Шалты авыл җирлеге
башкарма комитеты сәркатибе Валиев Э.А.